| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Әлмәле авылы

27 июль 2023 ел № 31/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»

2023 елның 13 июнендәге 258-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы федераль законнарга ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советының 30.05.2023 № 31/1 карары белән расланган Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 статьяның 5 пунктын "федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш" дип тулыландырырга;

19 нчы маддәнең 3 нче пунктында 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе яисә «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков